***Фаяз ДУНАЙ,***
*Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы*

# ЧИШМӘСЕ ДӘРЬЯГА КУШЫЛСЫН

Ул Чаллы-Чулман якларындагы Иштирәк дигән милли, матур исемле бер авылда туып үскән. Хәзер дә шул төбәкнең бүгенге яңа бизәкләрен, сулышын, моңын күреп-ишетеп, якташлары белән аралашып, алар тормышындагы хәрәкәт-үзгәрешләрне күзәтеп, сиземләп яши. Ул үзенең самими-беркатлы да, хыялый тәвәккәл, «таштабан» да булган балачагы, яшүсмер еллары турында да бик тә табигый моңлы сагыну, юмор белән парчалар яза...

Ул ихлас тырышлык белән «басылып укып», Казан дәүләт университетында төпле белем алган, һәм хәзер дә еш кына үзенең остаз-укытучыларын хөрмәтләп, аеруча хәзерге танылган язучыбыз, доцент Мөхәммәт абыйсы Мәһдиевне зурлап, аның педагогик осталыгына сокланып сөйли. Ул әле дә туктаусыз укый, өйрәнә. Аның рухы-җаны һәрдаим сәяхәтләрдә.

ВУЗны тәмамлагач та ул комсомол эшендә кайнап йөргән, аннары район газетасының киеренке мәктәбен узган. Ул хәзер дә, производство, гаилә-бала, көнкүреш, үз әдәби иҗаты мәшәкатьләре, кыенлыклары фәлән кадәр булса да, бер җәмәгать эшеннән дә баш тартмый.

Урта буйлы, чем кара бөдрә чәчле, кара тутлы, күзлекләре астыннан мут, көләч нур сирпелеп торган кара күзле бу ир-егет күп вакыт алга сөрлегебрәк, ритмик чайкалыбрак һәм бик ашыгып атлый. Әмма үзе бик тә күзәтүчән, күпне күреп, хәтеренә эләктереп алучан икән ләбаса!

«Инде орчык, тыштагы буран тавышына кушылып, бер төрле йокымсырата торган көйгә җай гына бөтерелә башлаган иде, инде шайтанның үзеннән дә кararак песи баласы, сандык өстенә менеп, бик дикъкать белән орчык әйләнгәнен күзәтә һәм, бөтерелергә хут биргәндәй, нәни тәпиләрен орчыкка таба сузгалап-сузгалап ала иде...» Яки менә «Хуҗа Насретдин» исемле хикәясеннән: «Фәсил су өстендәге башка шәүләләр арасыннан үз шәүләсен эзләп тапты. Иң озыны, шүредәй ябыгы – аның шәүләсе...»

Яшь әдип-прозаик Рафис .Сәлимнең язмаларыннан менә шундый, бары зирәк художник күзләре генә шәйләп, образлы сурәтли алган тәэсирле эскиз, бизәк-нюанс мисалларын күпләп китерергә мөмкин.

Ул да әдәбиятка җиңел атлап кына килә алмый. К. Маркс әйткәнчә, «йөрергә өйрәнгәндә кеше егылырга да өйрәнә, һәм бары тик егыла-тора гына, ул йөрергә өйрәнә...»

Безнең Рафис та менә шулай, күпчелек иҗат кешеләренә әллә фарыз, әллә табигый язмыш булганга, абына- тора зур тормыш, әдәбият юлына чыгарга тырыша.

Яшьлегендә «гыйшык-мәхәббәт сүрәләре» яки ялангач риторик-патетик шигырьләр язгандырмы — күрсәткәне, сөйләгәне юк, белмим. Әмма бер заман ул дистә еллар элегрәк Чаллыда уздырылган яшь язучылар семинарына шактый күләмле повесть күтәреп килде. Кыюлыгы да бар егетнең һәм дәгъва-ышанычлары да юк түгел. Әдәбиятта искечә язу туйдырды, янәсе, менә ул «яңача яза»! Менә «философик повесть»! Ишеткәч, муен чокырыңны кашып куярдай, шактый классик эстетик хәзинәләрне инкяр итәргә ниятле дорфа-кире мөһер сүзләр дә ычкынып китә егеттән. Кыскасы, яшьлекнең әле тормыш «сыеры аягына басмаган» тәҗрибәсез, әмма кайнар бер кыю-дуамал чоры. Һәм шундый елларда сырхаулап ала торган нигилистлык чире чыгып бетмәгән егеттән...

Дикъкать белән укып баккач, бәй, Рафисның әлеге бик тә тырышып-көчәнеп фәлсәфәлеккә, яңалыкка дәгъва кылган күләмле әсәре – ни укучыны мавыктырырлык фабула-сюжеты, вакыйгалары, ни бер төзек композициясе булмаган таркау язмалар гына булып чыкты. Аның «философиясе» я гап-гади Сөнгать абзый белән Гөлниса түтигә дә күптән мәгълүм әлиф кенә, я башкатыргыч абстракт-буталчык сүз тезмәләре, яисә гамәлдә чыпчык тезен дә күмә алмаслык өзек-өзек фикер кисәкләре генә...

Безнең Рафисыбыз (мөгаен, әле дә шактый яшьләрнең кимчелеге) инде 1931 елда ук язылган, рәсми университетлар бетерә алмаса да, гаять белемле, зирәк-бөек Һади Такташыбызның «Партиясез» һәм партияле шигырьләр турында»гы атаклы мәкаләсен дә я онытkан, яки санга сукмаган. Утыз яшьлек Такташ әле хәзер дә искиткеч хак-реаль булган менә нинди акыллы сүзләр язып калдырган лабаса!

«Безнең кайбер язучыларыбызда тагын бер авыру як бар, алар үзләренең әсәрләрендәге кечкенә генә әһәмияте булган бер фикерне гаҗәеп зур сүзләр белән, төрле фигуралар ясаган булып, кеше аңламаслык хәлгә китерәләр. Шигырьдә фикер никадәр аңлаешсыз «сложный» итеп әйтелсә, шулкадәр матур һәм көчле әйтелгән дип уйлыйлар. Хәтта андый аңлаешсыз шигырьләрне «фәлсәфи» шигырьләр дип йөртәләр».

Юк, без прозаик Рафис Сәлим генә сырхаулагандыр дип, бу чирне аның гына бәласе булгандыр, дип шәрә-калку итеп күрсәтергә ният тотмыйбыз – әле дә шундыйрак чир белән чирләүче әдип-шагыйрьләргә, аларның шул кимчелеген «фәлсәфи» дип бәяләргә ашыгучы, я тәҗрибәсез, я белеме чамалы булган тәнкыйтьчеләргә дә гыйбрәт, искәртү булсын өчен кабат кычкырып кабатлыйбыз! Янә борынгы аксиоманы тәкрарлыйбыз: юк шул, әдәбият-сәнгать әсәре салкын акыллы шәрә фикерләр, силлиогизмнар һәм хөкем-нәтиҗәләр тезмәсе түгел шул, егетләр, кызлар – ә кеше күңелен-җанын дәрьяларга да чумдыра, кыяларга да очыра алырдай, җырларга да, еларга да мәҗбүр итәрдәй, акыллы фикер-гыйбарәләр, канатлы сүзләр, кайнар хис, көй-моңнарның, мавыктыргыч киеренке вакыйгаларның, шәхес-персонажларның, образларның, кыскасы, күп компонентларның табигый органик бәйләнеше, чагылышы, казанышы ул!

Рафис Сәлимнең беренче әсәрләрен укыган өлкән иптәшләр бу яшь әдипкә бик тә игътибарлы, ярдәмчел булдылар, дисәм — ялгышмамдыр. Аның әлеге «шайтан да кул селтәрлек повестена» алар ярлы-чуар философия белән әдәбиятны кушып, ниндидер «оригиналь сумса» пешерергә өмет иткән зая мавыгу, гөнаһсыз парадокс итеп кенә карадылар, һәм... шул язмалар арасыннан ук бик тә табигый тормышчан, якты юморлы һәм бөтенләй аеры- мөстәкыйль унлап парча-новелла табып алдылар, авторның каләм куәтенә инандылар, киләчәгенә өмет багладылар.

Егет үзе дә гамьсез-ваемсызлардан булып чыкмады, күңелен төшермәде. Югарыда телгә алып узган «чир»не тормыш җиле тиз өреп очырды. Рафис Чаллы шәһәренә күченеп килде, эшнең агын-карасын эзләп йөрми, производствога кереп китте, промышленность, төзелеш технологиясен, авылдан шәһәргә күчкән якташларының кылган гамәлләрен өйрәнергә кереште, һәм илһамланып, инде хәзер үз максатын якты-ачык белеп, парчалар, хикәяләр язды. Матбугат хезмәткәрләре дә аңа игелекле, игътибарлы булдылар, Рафисның әсәрләре бер-бер артлы башта район, аннары республиканың газета-журналларында еш басыла башлады.

Менә инде без аның «Елан мөгезе» исемле җыентыгын да (Татарстан китап нәшрияты, 1984) сөенеп кулыбызга алдык. Җыентык (әлбәттә, әдип һәм шагыйрь Разил Вәлиевнең зур булышлыгы, химая итүе, зәвыгы да сизелә) үзенең тематика-хроникасы, композициясе белән шактый эзлекле, камил-отышлы төзелгән.

Рафис Сәлим — әлегә безнең өчен юморист, сатирик язучы. Шул тыйнак-җыйнак китаптагы парча-хикәяләрнең күпчелеге безнең әйләнә-тирә мохит-даирәбездәге шәхесләрнең гаеп-гөнаһларын, кимчелекләрен фаш итүгә багланган. Ләкин, вәт, хикмәт! Без нәфрәтләнеп сүгенмибез дә, каш-маңгай да җыермыйбыз, ә чын ихласлык белән көләбез, елмаябыз, моңланабыз, уйланабыз. Дөньябыз яктырып, куанычларыбыз артып киткәндәй була. Сер-хикмәт: ул әсәрләрнең. бик тә тормышчан-реаль булуларында, автор үзе күргәнне-белгәнне, ишеткәнне, кичергәнне яза. Хикмәт – авторның үзе фаш иткән шәхесләрне дә үз күреп, яратып, борчулы көлеп, җәлләп гәүдәләндерүендә. Хикмәт – Рафис Сәлимнең халык телен, бу телнең яңгырашын-көен, табигый синтаксис структурасын, орфоэпиясен, һәртөрле чит тел сүзләрен, неологизмнарны да үз «җылы кочагына» һәм үзенчә сыендыра алырга сәләтле булуын бик әйбәт белүендә, әдәбиятның төп коралы – тел икәнлеген бер генә җөмләсендә дә онытмавында.

Гадәттә, Рафис парча-хикәяне бик тә кыска, гади бер җөмлә – «телеграф теле» белән башлап китә. «Авылда грипп». («Грипп» хикәясеннән.) «Кич. Ай чыгып килә». («Трактор».) «Өстә тилгән әйләнә». («Бәбкә саклаганда».) «Үзгәрде дөнья!» («Безнең йорт кыйссасы».)

Икенче очракта, Рафис парча-хикәяне туп-туры диалогтан ук башлый: «– И, кызык та кеше инде син...» («Центр».) «Минем турыда язарга дисең, алайса, ә?» («Рационализатор».)

Өченче алым, Рафис әсәрне эчке монолог-уйланудан яки хат-хәбәр алымы белән башлый: «Анысы да бармыйм ди бит. Әйтерсең эшкә җибәрәләр...» («Алдынгылар слеты».) «Нишләп булмасын, бар дөньяда әйбәт кешеләр, бар. Әнә бит. Ничек соң әле исеме?...» («Яхшылык».)

Менә шундый гап-гади, ләкин әдәбиятта үзен бик аклаган ышанычлы-тылсымлы «ачкычлар» белән яшь язучы укучы күңеленә үрелә, аның игътибарын җәлеп итә дә, аннары аңа вакыйганың җирлеге-вакыты хакында кыска гына, ләкин образлы информация ясый да, сюжетны, хәл-әхвәлләрне дәвам итү «дилбегәсен», сүзне, димәк, холык-фигыльләрне ачу вазифасын персонажларның үзләренә тапшыра. Күпчелек очракта, нәкъ кино сценарие яки драматургиядәге сыман! Яшь авторның инде пьесалар язарга керешүе дә тикмәгә түгел.

Рафис Сәлим пейзажны, җирлек-фонны тасвирлау-сурәтләүгә бик саран. Аның метафоралары гади, ләкин ачык бизәкле, контрастлы. Ул күпчелек очракта соңгы ноктаны кайда, кайчан куярга кирәклеген үзләштергән инде. Ә менә диалог-монологлары, нәкъ менә укучыны һич

тыныч, битараф калдырмый торган байлыгы-осталы- гы, әйткәнебезчә, соклангыч табигый-тормышчан, алар – персонажларның характер көзгеләре! Менә шундый үзенчәлекле сыйфатлары белән яшь әдип беренче җыентыгында ук дистәдән артык менә дигән хикәяләр, парчалар иҗат итә алган, дистәдән артык шәхеснең портретын ачык сурәтли алган. Алар укучыларыбыз өчен бик тә таныш- гыйбрәтлеләр, алар – әдәбиятыбыз өчен сөенеч!

Ләкин яшь әдипнең әлеге җыентыгын, гомумән иҗатын «гел мәрҗәннәрдән генә торган дисбе-тәсбих икән» дип бәяләргә ашыкмыйбыз, җөрьәт итә алмыйбыз без.. Рафис Сәлим әле дә кимчелек-хаталардан, хафалардан һич азат түгел. Әйтик, ул кай ара монолог хикәяләүдә, персонажны тизрәк фаш итү белән мавыгып, битабигый «лобовой»-«маңгайга бәреп» эш итә, персонажның яшерен ниятен яшеребрәк сурәтли белми. Шул сәбәпле, аның берәр персонажы, авторга буйсынмыйча, тәмам тиле-дивана рәвешен ала яки икенчесе бик тиз шәп-шәрә күренеп торган сөмсезгә-нахалга әверелә. Җыентыкка кергән «Гыйбат белән Метри» яки «Центр» исемле хикәя- монологларда, безнеңчә, нәкъ шул хата үзен нык сиздерә. Яшь автор көнкүрешебез рәвешен, аеруча эчкечелекне фаш итү белән артык мавыга. Бу ямьсез хәл-әхвәл, бәлаләргә каршы көрәшергә кирәк, әлбәттә. Ләкин реаль чынбарлыгыбызны артык гиперболик чалшайтып, инде башка әдипләр күптән фаш иткән дәлилләрне янә кабатлап, эчкечелекне тормышыбызның чарасызлыгы-фатализмы дәрәҗәсенә күтәреп сурәтләргә һич ярамый, минемчә. «Чума» хикәясендә, безнеңчә, әнә шул бәла ята.

Тормыш материалына ярлы булмаган, әйткәнебезчә, туктаусыз эзләнүчән, талантлы яшь әдипкә киләчәктә гомумән үз иҗатының тематикасын баету, аны җитди ачыклау, магистраль платформаларга бастыру хакында нык уйланырга кирәк булыр.

– Юмористка нинди сыйфатлар кирәк? – дигән сорауга Латин Америкасының дөньяга танылган язучысы, Халыкара Ленин премиясе лауреаты Мигель Отеро Сильва түбәндәге сыйфатларны шарт итеп куя: новаторлык, бунтарьлык, хыялга бай булу, реализм һәм кешеләрне бик яратуны...

Әлегә аванс бирү кебегрәк булса да, тәвәккәлләп әйтик: безнең Рафис Сәлимдә бу зарур сыйфатларның шактые мәгълүм дәрәҗәдә бар. Ул – юлда, һаман эзләнүләрдә. Ак юл телик, нәтиҗәле иҗади гомер телик аңа!

*1990 ел*